МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.02.2015 г.Казань № 23/2-пр-а

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” 2012 елның 4 декабрендәге 1257 номерлы, “Үсемлекчелекнең аерым тармакларына ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 12 декабрендәге 1295 номерлы, “Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең сатылган товар сөтнең 1 литрына (килограммына) чыгымнарыныц бер өлешен каплау очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елныц 22 декабрендәге 1370 номерлы, “Үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә бәйләнешсез ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 27 декабрендәге 1431 номерлы күрсәтмәләрен үтәү максатында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка 1 нче кушымтаның 6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“милектә, арендада яки башка законлы нигездә авыл хуҗалыгы культураларын чәчү мәйданнары булуын раслый торган документлар.”;

1.2. Боерыкка 1 нче – 6 нчы кушымталарның 13 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартларының,

максатларының һәм тәртибенең үтәлүен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшереп торалар.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов